**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422620 Державиноо авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

**СОВЕТ ДЕРЖАВИНОСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620 с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**2022елның «17» ноябре** **38 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегендә Державино торак пункты гражданнары җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державино авыл җирлегенең Державино торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яшәү урыны буенча Лаеш муниципаль район Державино авыл җирлегенең Державино торак пункты территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән(көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш)1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Державино торак пунктындагы Агайбаш урамы территориясен су белән тәэмин итү системаларын реконструкцияләү (материаллар сатып алу һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- православие зиратын төзекләндерү һәм аңа керү юлларын төзү.

3. Әлеге карарны Державино авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)
.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державиноо авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ И.И. Камалиева**

**Башлык-Державино авыл җирлеге**
**Советы рәисе: _________________ И.И. Камалиева**